ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 21.03.2018 | г. Иннополис | № 15 КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә профилактик эш төркеме төзү турында

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы территориясендә “Торак - 2018” күзәтчелек-профилактика операциясен үткәрү турында” 2018 елның 19 февралендәге 175 номерлы карарын үтәү йөзеннән, янгыннар белән хәлне тотрыкландыру һәм аларда кешеләр һәлак булу, хокукый агарту һәм халыкка торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре турында хокукый мәгълүмат бирү рәвешендә профилактик чаралар үткәрү, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты гражданнары арасында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау максатларында,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә янгынга каршы пропаганда турында халыкка хокукый мәгълүмат бирү буенча профилактик эш төркеме составын расларга (Кушымта).

2. Профилактик эш төркеменә:

- Иннополис шәһәре чикләрендә торак секторның профилактик төркемнәренә беркетергә һәм аларның көче белән халыкка хокукый белем бирү һәм торак фондта һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре турында хокукый мәгълүмат бирү, янгынга каршы пропаганда формаларында профилактик чаралар үткәрергә;

- профилактик төркемнәр эшендә балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район комиссияләре белән күпбалалы гаиләләрдә, социаль

яклау органнарының попечительләр хисабында торучы гаиләләрдә профилактик чаралар эшен оештыру өчен хезмәттәшлек итәргә;

- ялгыз өлкән яшьтәге гражданнар, социаль яктан имин булмаган халык катламнары һәм амораль яшәү рәвеше алып баручы затлар белән эш оештырырга;
- 2018 елның октябренә кадәр Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәренең торак секторына тикшерү үткәрергә;
- атна саен җомга көннәрендә Югары Ослан муниципаль районының Иннополис шәһәренең торак секторын тикшерү нәтиҗәләрен Югары Ослан муниципаль районы буенча МЧС һәм Россия ГТХМ Баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырырга кирәк.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.Р. Шагалеев

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының ______ ________ карарына кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә торак фондында һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгының мәҗбүри таләпләре, янгынга каршы пропаганда турында халыкка хокукый мәгълүмат бирүнең профилактик эш төркеме составы

Профилактик эш төркеме рәисе

| | |
|---|---|
| Марат Әзһәр улы Гыйльфанов | «Татарстан Республикасы буенча 8 ОФПС» ФДМУнең 8 нче янгын-коткару часте башлыгы урынбасары, эчке хезмәт майоры (килешү буенча) |

профилактик эш төркеме әгъзалары

| | |
|---|---|
| Андрей Юрьевич Нижегородов | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, төзелеш һәм архитектура бүлеге башлыгы |
| Хөҗҗәтов Илдар Равил улы | Иннополис шәһәре Башкарма комитетының социаль һәм торак сәясәте бүлеге башлыгы |
| Галеев Рузель Илнур улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» полиция өлкән участок уполномоченные, полиция капитаны (килешү буенча) |